ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чаралары планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чаралары планын (кушымта итеп бирелә) расларга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 13 октябре
№ 2157-VI ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2023 елның 13 октябрендәге
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чаралары планы**

| № т/б | Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы тәкъдимнәр | Гамәлгә ашыру буенча чаралар | Үтәү срогы | Башкару өчен җаваплы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Махсус хәрби операциянең беренче көннәреннән үк татарстанлылар фронтның алгы сызыгындагы ватандашларыбызга, шулай ук шефлыкка алынган Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләренә актив ярдәм күрсәтә. Республикадан җибәрелгән гуманитар ярдәмнең гомуми күләме бүгенге көнгә 4 мең тоннадан артып китте. Моннан тыш, без Татарстанда формалаштырылган барлык бүлекчәләрне кирәкле корал һәм техника белән тәэмин итәбез. | 1.1. Луганск Халык Республикасына һәм Донецк Халык Республикасына гуманитар ярдәм җыю һәм аны җибәрү эшен оештыруда катнашу. | 2023, 2024 еллар дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат берләшмәләре |
| 2. | Махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаиләләре, аеруча һәлак булган сугышчыларның гаиләләре турында кайгырту гаять мөһим. Республикада төрле яклап ярдәм күрсәтү, шул исәптән балаларның ялын оештыру һәм аларны савыктыру, балалар бакчаларында урыннар бирү, ата-аналарны түләүдән азат итү, мәгариф оешмаларында бушлай кайнар ризык белән туклandыруны булдыру, шулай ук социаль, юридик һәм психологик ярдәм күрсәтү эше җайга салынды.<br>Тагын бер кат әйтәм, махсус хәрби операциядә | 2.1. «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалы белән махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләре мәнфәгатьләрендәге мәсьәләләрне хәл итүдә хезмәттәшлек.<br><br>2.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының күчмә утырышында «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы | ел дәвамында<br><br>2023 елның ноябре – декабре | С.М. Захарова<br><br>Ш.Ш. Яһудин |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | катнашучылар һәм аларның гаиләләре тормышындагы бер генә кыен хәл дә игътибардан читтә калырга тиеш түгел. Килеп туган мәсьәләләрне тиз арада һәм сыйфатлы хәл итү, «Ватанны саклаучылар» дәүләт фондының республикада быел төзелгән филиалына мөмкин булганча ярдәм күрсәтү – барлык дәрәҗәдәге хакимият органнарының, предприятиеләребезнең, оешмаларыбызның бурычы. | Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру барышы хакында»гы мәсьәләне карау. | | |
| 3. | Көнбатыштан илебез яшьләренә тискәре идеологик йогынты ясау омтылышлары элеккечә дәвам итә. Традицион рухи хәзинәләрне юкка чыгаруга, тарихи хәтерне бозып күрсәтүгә аеруча басым ясала.<br>Әлеге шартларда ватанпәрвәрлек тотрыклылыгыбызның какшамас нигезен тәшкил итәргә тиеш. Массакүләм мәгълүмат чараларына нәкъ менә шушы фикерләрне тарату мөһим, мәдәният һәм сәнгать әһелләренең әсәрләре шуларга нигезләнергә тиеш.<br>Бу эштә балаларның һәм яшүсмерләрнең «Яшь армия», «Зур тәнәфес» дигән иҗтимагый берләшмәләренә, «Авангард» хәрби-патриотик тәрбия бирү буенча укыту-методик үзәкләренә, волонтерлык отрядларына һәм оешмаларына зур роль бирелә.<br>Илебез Президенты башлангычы белән «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия балалар һәм яшьләр оешмасы төзелде. Аның төп бурычлары – яшь буында илебез белән горурлану, Ватанны ярату хисе тәрбияләү, тарихи хәтерне саклау.<br>Татарстан бу эштә актив катнаша: барлык муниципалитетларда җирле һәм башлангыч | 3.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты тарафыннан «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына әзерләү.<br><br>3.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык сигезенче утырышында Татарстан Республикасы Дәүләт Советында тәкъдим ителмәгән сәяси партияләр катнашында «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» Татарстан Республикасы законы проектын карау.<br><br>3.3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы утырышында «Татарстан Республикасында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү турында» 2023 елның 22 июнендәге 2025-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарын үтәү барышы | 2023 елның октябре – ноябре<br><br>2023 елның октябре<br><br>2024 елның июне | А.Р. Зарипов<br><br>А.Р. Зарипов<br><br>А.Р. Зарипов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | бүлекчәләр төзелде, бик күп яшьләр катнашында чаралар уздырыла.<br>Шунысын да әйтергә кирәк, яшь буынга тәрбия бирү – бер генә көнлек эш түгел. Балалар бакчаларының өлкән төркемнәре тәрбиячеләренә, мәктәпләрдә сыйныф җитәкчеләренә һәм урта махсус уку йортлары һәм югары уку йортларының хезмәткәрләренә зур җаваплылык йөкләнә.<br>«Беренчеләр хәрәкәте»нең барлык дәрәҗәдәге җитәкчеләренең игътибарын бу очракта формаль эш итәргә ярамавына юнәлтәм. Яшь буынны тәрбияләүгә ихлас мөнәсәбәт булганда гына без киләчәккә ышаныч белән карый алачакбыз.<br>Һичшиксез, балада ватанпәрвәрлек хисе, рухи-әхлакый хәзинәләргә тугрылык, иң беренче чиратта, гаиләдә тәрбияләнә. Гаиләнең әһәмияте бәяләп бетергесез. Нәкъ менә гаиләдә халкыбызга хас булган җиргә, туган йортка мәхәббәт, тугрылык һәм үзара хөрмәт, эш сөючәнлек һәм җаваплылык кебек сыйфатларга нигез салына. | хакында»гы мәсьәләне карау.<br><br>3.4. «Гаилә кыйммәтләрен, аңлы рәвештә ана булуны формалаштыру. Заманча гаиләләрнең кыйммәтләре һәм билгеләмәләре» темасына «түгәрәк өстәл». | 2024 елның июле | А.Р. Нәбиева |
| 4. | Тарихи хәтерне саклау – безнең изге бурычыбыз. | 4.1.Татарстан парламентының элекке җитәкчеләренең җирләнү урыннарын төзекләндерү һәм анда бару. | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең мәгълүмат-методика бүлеге |
| 5. | Быел гына да республикада 22 Советлар Союзы һәм Россия Федерациясе Героена, шул исәптән махсус операциядә катнашучыларга һәйкәлләр, бюстлар һәм мемориаль такталар куелды. Ватан Геройлары истәлеген мәңгеләштерү эшен, һичшиксез, киләчәктә дә | 5.1. «ТНВ» депутат төркеме җыелышында «түгәрәк өстәл» форматында «Ватанны саклаучыларның, шулай ук Татарстан Республикасы үсешенә өлеш керткән танылган шәхесләрнең истәлеген саклауга һәм мәңгеләштерүгә юнәлдерелгән чаралар» | 2024 елның II кварталы | А.Р. Габделҗанов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | дәвам итәчәкбез.<br>2025 елда илебез Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итәчәк. Хөкүмәткә, шәһәр һәм район башлыкларына инде хәзердән үк юбилей датасын бәйрәм итүне оештыру эшен башларга кирәк. | мәсьәләсен карау.<br><br>5.2. Муниципаль районнарда Россиянең героик үткәненә багышланган стелаларны, һәйкәлләрне һәм мемориал такталарны торгызу эшләрен оештыру. | ел дәвамында | Х.Г. Миргалимов |
| 6. | Киләсе елның язында Россия Федерациясе Президентын сайлау узачак. Бүген илебез читтән янаган куркынычларга каршы тора, һәм алар җәмгыятебезнең берләшүенә тагын бер этәргеч булыр, ә татарстанлылар сайлау кампаниясе барышында югары активлык һәм илкүләм лидерыбызның хәзерге курсына теләктәшлек күрсәтерләр дип ышанам.<br>Киләсе елның сентябрендә республика Дәүләт Советының җиденче чакырылышы сайланачак. | 6.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты утырышында «2024 елда Россия Федерациясе Президентын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны уздыруны законнар белән һәм оештыру ягыннан тәэмин итү турында»гы мәсьәләне карау. | 2024 елның I кварталы | А.Г. Хәбибуллин |
| | | 6.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты утырышында «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җиденче чакырылыш депутатларын сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын тоту турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе хисабы хакында»гы мәсьәләне карау. | 2024 елның IV кварталы | Л.А. Якунин |
| | | 6.3. Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү, гражданнарны кабул итү, сайлаучылар белән очрашулар. | 2023, 2024 еллар дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| 7. | Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин рәислегендәге Дәүләт Советы, тирәнтен уйланган дөрес карарлар кабул итеп, республиканың һәм аның гражданнарының мәнфәгатьләрен һәрчак яклый килә. | 7.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы утырышында «Татарстан Республикасында гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә | 2024 елның марты | А.К. Хамаев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 21 июнендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына мониторинг ясау нәтиҗәләре хакында»гы мәсьәләне карау.<br><br>7.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы утырышында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашыру өлешендә «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына мониторинг ясау нәтиҗәләре хакында»гы мәсьәләне карау. | <br><br><br><br><br><br>2024 елның апреле | <br><br><br><br><br><br>А.Г. Хәбибуллин |
| 8. | Безгә киләчәктә дә мәдәни байлыгыбызның, ата-бабаларыбыз турындагы хатирәләрнең саклануы, һәр халыкның үзенчәлеге киләсе буыннарда да дәвам итсен өчен уртак тырышлык куярга кирәк. Шул рәвешчә генә без ата-бабаларыбыздан мирас булып калган кабатланмас мәдәни үзенчәлегебезне саклый алачакбыз. Бу эштә, һичшиксез, мәдәният һәм сәнгать әһелләренә мөһим роль бирелә. | 8.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышында Казан дәүләт консерваториясе базасында «Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фәнни-белем бирү кластерын үстерү турында»гы мәсьәләне карау. | 2024 елның июне | А.Р. Зарипов |
| 9. | Яшь буын өчен мәдәни үсешне генә түгел, бәлки, белем һәм тәрбия бирү юнәлешен дә игътибар үзәгендә тотарга кирәк. Сүз мәгариф һәм тәрбия программаларына «Халык традицияләре» модулен кертү, системалы нигездә халык һөнәрчелеге буенча осталык дәресләре, курслар уздыру, балалар өчен укыту-күрсәтмә әсбаплар булдыру турында бара.<br>Казанда Халык сәнгать һөнәрчелеген, кәсепчелеген һәм декоратив-гамәли сәнгатен торгызу, саклау, өйрәнү һәм үстерү үзәге ачылу | 9.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында «Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында» 2005 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына мониторинг ясау хакында»гы мәсьәләне карау. | 2023 елның декабре | А.Р. Зарипов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | бу юнәлештә җитди ярдәм булырга тиеш. | | | |
| 10. | Татарстан Республикасы, традицион рухи хәзинәләргә, тарихи-мәдәни мираска тугры калып, дөньяда гадел багланышлар урнаштыруны яклый килеп, чит ил партнерлары белән халыкара хезмәттәшлекне үстерүне дәвам иттерә.<br>Бу юнәлештә Kazan-Forum халыкара икътисадый форумы нәтиҗәле мәйданчыкка әверелде. Уздырылган чаралар ил җитәкчелеге тарафыннан югары бәяләнде. Быел анда сиксәннән артык чит ил вәкиле катнашты. Бу исә Россиянең дөнья белән бәйләнешләрен өзү мөмкин түгеллеген тагын бер кат раслады. Kazan-Forumны киләсе елда югары дәрәҗәдә уздыруны тәэмин итәргә кирәк.<br>Моннан тыш, Ислам хезмәттәшлеге оешмасы белән төрле юнәлешләрдә, шул исәптән дөнья күләмендә яшьләргә кагылган гамәлләр, фән, мәдәният, мәгариф, спорт даирәсендә, шулай ук хәләл тормыш рәвеше алып баруга шартлар тудыру өлкәсендә хезмәттәшлекне дәвам иттерү зарур.<br>Илебез Президенты 2024 елда Казанда егермедән артык ил лидеры катнашачак БРИКС һәм БРИКС+ дәүләт башлыклары саммитын уздыру турында указга кул куйды. Безнең өчен бу зур дәрәҗә булу белән бергә, бик зур җаваплылык та.<br>Саммит кысаларында бик күп чаралар, шул исәптән мультиспорт чаралары – БРИКС уеннары узачак. Безнең алда куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм кунаклар кабул итүгә әзерлек буенча җитди эшләр тора. Республика оештыру комитетына федераль | 10.1. Халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары эшчәнлеген хокукый җайга салу өлешендә «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләү һәм кабул итү.<br><br>10.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының БРИКС саммиты, «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» XIV икътисадый форумы, «Киләчәк уеннары» турниры, «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» халыкара форумы, БРИКС уеннары кысаларында уздырыла торган чараларда катнашуы. | 2023 елның IV кварталы<br><br>2024 ел дәвамында | А.Г. Хәбибуллин<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | дәрәҗәдәге хезмәттәшләре белән берлектә аны координацияләүне оештырырга кирәк. | | | |
| 11. | Республика икътисады, тулаем Россиядәге кебек үк, тышкы сынауларга бирешми һәм тотрыклы булып кала. Бу елның төп социаль-икътисадый үсеш күрсәткечләрендә уңай динамика күзәтелә. Әлеге нәтиҗәләр күпчелектә алдагы елларда тупланган көч, федераль һәм республика күләмендә оператив төстә кабул ителгән ярдәм чаралары нәтиҗәсендә мөмкин булды.<br>Алга таба да барлык тармак предприятиеләренең өзлексез эшен тәэмин итәргә кирәк. Министрлыкларның, ведомстволар, муниципалитетлар һәм депутатларның бурычы – бизнеска максималь ярдәм күрсәтү, һәр җитештерүченең сорауларына игътибар бирү, предприятиеләргә дәүләт тарафыннан күрсәтелә торган ярдәм турында мәгълүмат бирү һәм аларның эшенә җитәкчелек итү. | 11.1. «2024 елга һәм 2025, 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасының җыелма бюджеты һәм 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразы проекты буенча парламент тыңлаулары һәм зона киңәшмәләре.<br><br>11.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты утырышларында «Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында хисап хакында»гы мәсьәләне квартал саен карау. | 2023 елның октябре<br><br>2024 елның апреле, августы, октябре | Л.А. Якунин<br><br>Л.А. Якунин |
| 12. | Россия Президенты куйган бурычларның иң әһәмиятлеләреннән берсе – төп тармакларда технологияләр буенча бәйсезлеккә ирешү һәм җитештереп тәкъдим итү икътисады булдыру. | 12.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты депутатларының Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше стратегиясен һәм «Россия Федерациясендә технологик компанияләрне үстерү турында» 2023 елның 4 августындагы 478-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыруда катнашуы.<br><br>12.2. «Мәрхәмәт – Милосердие» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы хатын-кыз депутатлар берләшмәсенең күчмә утырышында «Татарстан Республикасында яшь галимнәргә дәүләт ярдәме чаралары | 2023, 2024 еллар дәвамында<br><br>2024 елның феврале | Л.Н. Шәфигуллин<br><br>А.Р. Нәбиева |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | турында»гы мәсьәләне карау (А.Н. Туполев исемендәге КНИТУ – КАИ базасында). | | |
| 13. | Квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү – икътисад үсешенең иң әһәмиятле факторларының берсе. Әлеге бурычны хәл итү, барлык төп компонентларны колачлаган төстә, системалы алып барылырга тиеш.<br>Эшне мәктәптән үк башларга кирәк. Соңгы елларда БДИ бирү өчен профильле математика, физика һәм химия кебек юнәлешләрне сайлаучы мәктәп укучылары санының кимүе кебек хәвефле күренеш күзәтелә. Әлеге хәлне үзгәртү зарур. Моның өчен һөнәр сайлауда дөрес юнәлеш бирергә, предприятиеләр катнашында юнәлеш сайлаганчы һәм юнәлеш сайлаганнан соң укыту эшен җайга салырга, балаларны иҗади, уйлап табу эшчәнлегенә җәлеп итәргә кирәк. Бу эштә һөнәр белән кызыксынуны арттыра торган чемпионатлар хәрәкәтенә һәм конкурс чаралары уздыруга аерым роль бирелә.<br>Белгечләр әзерләү тәгаен предприятиеләр ихтыяҗларын исәпкә алып барылырга тиеш. Бу максатларда республикада 47 ресурс үзәге эшли. Әлеге модель үзенең нәтиҗәле булуын раслады инде.<br>Моннан тыш, «ПОЗиС» заводы өчен белгечләр әзерләүче Зеленодольск механика көллиятендә җитештерүдә эшкә өйрәтү кластеры булдырылды.<br>Суднолар төзү тармагын кадрлар белән тәэмин итү максатларында Зеленодольск суднолар төзү көллияте ачылды.<br>Чаллының ресурс үзәкләре белән «КАМАЗ» компаниясе актив эшчәнлек алып бара.<br>Алдынгы инженерлык мәктәпләрен ачу | 13.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында «Агросәнәгать комплексы өчен квалификацияле кадрлар әзерләү турында»гы мәсьәләне карау. | 2024 елның марты | А.К. Хамаев |
| | | 13.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының күчмә утырышында «Татарстан Республикасы сәнәгатенең әһәмиятле тармакларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү, компетенцияләр үзәкләрен булдыру чаралары турында»гы мәсьәләне карау (Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе базасында). | 2024 елның мае | Л.Н. Шәфигуллин |
| | | 13.3. «ТНВ» депутат төркеме җыелышында «түгәрәк өстәл» форматында «Татарстан Республикасы сәнәгать өлкәсе предприятиеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү чаралары турында»гы мәсьәләне карау («КАМАЗ» компаниясенең һәм «Ак Барс» суднолар төзү корпорациясенең ресурс үзәкләре белән эш тәҗрибәсе). | 2024 елның II кварталы | А.Р. Габделҗанов |
| | | 13.4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында «Татарстан Республикасында һөнәри юнәлеш буенча эш, алдан профильле әзерлек һәм | 2024 елның сентябре | А.Р. Зарипов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | киләчәге өметле проект булып тора. Машина төзелеше (КФУ һәм «КАМАЗ»), нефть химиясе (КХТИ һәм «СИБУР»), ИТ-өлкәдә (Иннополис Университеты ИТ-компанияләр белән берлектә) һәм биотехнологияләр (ИТМО, АГНИ «Татнефть» компаниясе белән берлектә) өлкәсендә 4 мәктәп үз эшчәнлеген башлады инде.<br>Моннан тыш, республика Хөкүмәтенә Фәннәр академиясе, предприятиеләр, Югары уку йортлары ректорлары шурасы белән бергәләп авиация һәм вертолетлар төзү, төзелеш, авыл хуҗалыгы, медицина технологияләре өлкәләрендә компетенцияләр үзәкләрен булдыру эшен дәвам иттерергә кирәк. | профильле уку турында»гы мәсьәләне карау. | | |
| 14. | Югары уку йортларыбыз алдында югары уку йортлары даирәсендә технологик эшкуарлыкны үстерү, дөнья дәрәҗәсендәге фәнни-мәгърифәти үзәкләр төзү буенча федераль проект, шулай ук «Өстенлек-2030» стратегик лидерлык федераль программасы кысаларында эшне активлаштыру бурычы тора. | 14.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүгә керткән өлеше хакында хисап турында»гы мәсьәләне карау.<br><br>14.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Единая Россия» депутат фракциясе утырышында «Татарстан Республикасында Фәнни-технологик үсеш елы йомгаклары турында»гы мәсьәләне | 2024 елның феврале<br><br>2024 елның IV кварталы | А.Р. Зарипов<br><br>Ю.З. Камалтынов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | карау. | | |
| 15. | Тулаем алганда, төп өстенлекләр һәм киләчәк эш юнәлешләре республиканың кабул ителгән Фәнни-технологик үсеше программасында чагылыш таба. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе аны гамәлгә ашыруга идарә итүне берләштерүче үзәк булып торырга тиеш. Хөкүмәтебезгә әлеге өлкәдә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең вәкаләтләрен ныгыту һәм аның ресурслар белән тәэмин ителешен көчәйтү буенча тиешле тәкъдимнәр кертү зарур.<br>Фәннең һәм инновацияләрнең алдыбызда торган бурычларны хәл итүдә мөһим ролен аңлап, Россия Федерациясендә Фән һәм технологияләр унъеллыгы, Россия фәненең 300 еллыгы кысаларында киләсе елны Татарстан Республикасында Фәнни-технологик үсеш елы дип игълан итәм. | 15.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хисабы турында»гы мәсьәләне карау. | 2024 елның марты | А.Р. Зарипов |
| 16. | Бизнесны үстерү өчен уңайлы шартлар булдыру – безнең алда торган иң өстенлекле бурычларның берсе. Киләчәктә әлеге юнәлештә эшне дәвам итү өчен безнең мөмкинлекләребез бар. Беренче чиратта, бу инвестиция проектларын гамәлгә ашыру белән бәйле процедураларны узу вакытын һәм документлар санын киметүгә кагыла. | 16.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты утырышында «Республикада бизнес алып бару өчен уңай шартлар тудыру һәм инвестицияләр агымын арттыру чаралары турында, шул исәптән бизнес һәм дәүләт хакимияте органнарының үзара хезмәттәшлеге юлы белән» мәсьәләсен карау. | 2024 елның ноябре | Л.Н. Шәфигуллин |
| 17. | Кече һәм урта бизнес – икътисад төзелешен үзгәреп коруда төп корал.<br>Эшкуарлык мохитен яхшырту, аерым алганда яңа кече һәм урта предприятиеләр субъектлары булдыруга кызыксынганлык тудыру, бизнесның югары сыйфатлы үсешен, аның икътисадның | 17.1. «Цифрлы технологияләр, цифрлы хезмәт күрсәтүләр булдыру өлкәсендә кече һәм урта бизнесны үстерү перспективалары турында. Законнар белән тәэмин итү» темасына матбугат конференциясе уздыру. | 2023 елның ноябре | Л.Н. Шәфигуллин |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | киләсе баскычына – вак компанияләрдән кече компанияләргә, кече компанияләрдән урта компанияләргә күчешен тәэмин итү, икътисадның реаль секторы – җитештерүчеләребезнең бизнесын үстерү, шулай ук эшкуарларга чит ил базарларына чыгуга ярдәм итү һәм үз сәүдә маркаларын танытуга комачаулаучы чикләүләрне бетерү безнең өчен өстенлекле бурыч булып тора.<br>Моннан тыш, сәнәгать паркларының, цифрлы нигезгә корылган сервисларның, шул исәптән Республика маркетинг үзәге, МСП.РФ федераль цифрлы платформаның, шулай ук интернет-сәүдә мәйданчыкларының мөмкинлекләреннән активрак файдаланырга кирәк. | 17.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының күчмә утырышында «Татарстан Республикасында муниципаль дәрәҗәдәге кече һәм урта бизнесны һәм сәнәгать мәйданчыкларын үстерү өлкәсендә норматив хокукый актларны үтәү турында»гы мәсьәләне карау.<br><br>17.3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Бюджет, салымнар һәм финанс комитетының күчмә утырышында «Алексеевск» сәнәгать паркында региональ салым ташламаларыннан нәтиҗәле файдалану турындагы мәсьәләне карау. | 2024 елның июне<br><br>2024 елның IV кварталы | Л.Н. Шәфигуллин<br><br>Л.А. Якунин |
| 18. | Төп бурыч – терлекләрнең баш саны кимүгә юл куймау. Безнең агрохолдинглар тарафыннан терлекләрнең баш санын торгызу, яңа терлекчелек комплекслары төзү буенча юл карталары кабул ителде. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының бурычы – аларның үтәлешенә контрольне тәэмин итү. | 18.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чаралар хакында»гы мәсьәләне карау.<br><br>18.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын үтәү турында, шул исәптән авылларда авыл хуҗалыгы кулланучылар | 2024 елга зона семинар-киңәшмәләрен үткәрү графигы нигезендә<br><br>квартал саен | А.К. Хамаев<br><br>А.К. Хамаев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | кооперациясен үстерү өлешендә» мәсьәләсен карау. | | |
| 19. | Һәр елны сәнәгать предприятиеләренең цифрлы үсешен бәяләү уздырыла. Бирелә, гадәттәгечә, «КАМАЗ», «Татнефть», «Татэнерго» оешмалары алдынгылыкны бирми. Ләкин цифрлы технологияләрне җитәрлек дәрәҗәдә кулланмаучы компанияләр дә бар. Тагын бер кат җитәкчеләрнең игътибарын шуңа юнәлтәсем килә: цифрлаштыру хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруда һәм конкурентлыкны үстерүдә мөһим фактор булып тора. | 19.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының күчмә утырышында «Татарстан Республикасы икътисадының җитештерү секторында хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруда һәм конкурентлыкны үстерүдә фактор буларак цифрлы технологияләр кертү турында»гы мәсьәләне карау («Татнефть» гавами акционер җәмгыяте базасында). | 2024 елның июле | Л.Н. Шәфигуллин |
| 20. | Безнең эшебезнең төп нигезе – халыкның тормыш сыйфатын яхшырту. Әлеге максат белән Татарстанда илкүләм проектлар һәм республика программалары кысаларында киң колачлы планлы эш алып барыла.<br>Ел ахырына кадәр тулаем республика буенча 725 күпфатирлы йортта капиталь төзекләндерү эшләре тәмамланачак.<br>«Безнең ишегалды» программасын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә бик күп уңай фикерләр ишетәбез (ел саен меңгә якын ишегалды тәртипкә китерелә), шулай ук җәмәгать урыннарын төзекләндерү эшләре башкарыла. | 20.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты утырышында «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру барышы хакында»гы мәсьәләне карау. | 2024 елның I кварталы | А.В. Тыгин |
| 21. | Гамәлгә ашырыла торган программаларның һәм проектларның нәтиҗәлелеген арттыруда иң мөһиме – аларның территорияләрне комплекслы үстерү максатларында бер үк вакытта гамәлдә булуын тәэмин итү.<br>Беренче чиратта, бу торак, транспорт, инженерлык һәм социаль инфраструктура төзүгә карый. Бирелә төп роль Иҗтимагый киңлекләрне планлаштыру институтына бирелә. | 21.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы утырышында «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге законнарның аерым нигезләмәләренә мониторинг ясау йомгаклары турында»гы мәсьәләне карау.<br><br>21.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетының күчмә утырышында «Шәһәр төзелешен нәтиҗәле планлаштыру | 2024 елның сентябре<br><br>2024 елның III кварталы | А.В. Тыгин<br><br>А.В. Тыгин |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | турында»гы мәсьәләне карау (Казан агломерациясен үстерү мисалында). | | |
| 22. | Казан – Оренбург федераль трассасына тоташачак Алексеевск – Әлмәт юлын төзүне тәмамлау 2024 елга бурыч булып тора. Киләсе этап – Әлмәт – Баулы участогында юл төзелешен дәвам итү. Проектны гамәлгә ашыру Казан һәм Әлмәт агломерацияләре арасында югары тизлектә хәрәкәт итү мөмкинлеге бирәчәк.<br>Стратегик бурычыбыз – М-7 һәм М-5 федераль трассаларын беренче категория юллар белән бергә тоташтыру. | 22.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетының күчмә утырышында «Юл инфраструктурасын нәтиҗәле үстерү турында»гы мәсьәләне карау (республика районнарының берсе мисалында). | 2024 елның II кварталы | А.В. Тыгин |
| 23. | Җәмәгать транспортын үстерү – тагын бер мөһим юнәлеш. Илебез җитәкчеләре ярдәме белән хәрәкәт составын яңарту мөмкинлеге барлыкка килде. Якын арада Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Зеленодольск, Алабуга, Бөгелмә, Лениногорск, Зәй, Азнакай, Минзәлә, Нурлат һәм Баулы шәһәр һәм шәһәр яны маршрутлары өчен уңайлыклары булган 400дән артык заманча автобус сатып алыначак. Транспорт министрлыгына муниципалитетлар белән берлектә аларны маршрутларда нәтиҗәле файдалануны тәэмин итәргә кирәк. Бу автобус паркының дүрттән бер өлешен яңарту мөмкинлеге бирәчәк. | 23.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы утырышында «Татарстан Республикасында пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендәге законнарны мониторинглау йомгаклары турында» 2022 елның 15 сентябрендәге 1553-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарын үтәү барышы хакында»гы мәсьәләне карау.<br><br>23.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы утырышында «Татарстан Республикасы халкын транспорт белән тәэмин итү турында» 2023 елның 13 июлендәге 2088-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарын үтәү барышы хакында»гы мәсьәләне карау. | 2023 елның октябре<br><br>2024 елның июле | А.В. Тыгин<br><br>А.В. Тыгин |
| 24. | Торак фондына идарә өлкәсе шулай ук төп игътибар үзәгендә булырга тиеш. Элеккечә үк идарәче компанияләргә, аларның техник тәэминатына һәм кадрлар составына | 24.1. «Торак-коммуналь хуҗалыкта проблемалар турында» темасына «түгәрәк өстәл». | 2024 елның марты | Х.Г. Миргалимов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | кагылышлы сорауларыбыз бар әле. Муниципалитетларга, Дәүләт торак инспекциясенә аларның эшен катгый рәвештә контрольдә тотуны йөклим. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь министрлыгына федераль үзәк белән берлектә идарәче компанияләргә лицензияләр бирү таләпләрен тагын да кырысландыруга кагылышлы законнар эшләү мәсьәләсен карап тикшерүне йөклим. | 24.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты утырышында «Халыкка сыйфатлы торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр турында. Закон чыгару аспектлары» мәсьәләсен карау. | 2024 елның I кварталы | А.В. Тыгин |
| 25. | Белем һәм тәрбия бирү системасын өзлексез рәвештә камилләштерү – һәр илнең уңышлы киләчәге, технологик үсеш ягыннан алдынгылыгы нигезе.<br>Матди-техник базаны яхшырту белән берлектә, тармак программаларын тормышка ашыруга һәм кадрлар әзерләүгә зур акчалар бүлеп бирелә. Шуның белән берлектә, бертигез мөмкинлекләр бирелүгә дә карамастан, без дәүләт аттестациясе узучыларның нәтиҗәләре төрле булуын күрәбез. Тукай, Ютазы, Лаеш, Буа һәм Менделеевск районнарында БДИ нәтиҗәләре, тулаем республика буенча алганда, уртачадан түбәнрәк. Моннан тыш, быел имтиханнарын 100 баллга тапшырган бер генә укучы да булмаган, шулай ук мәктәпне тәмамлау турында аттестат бирелмәгән укучылар булган районнар да бар. Бу – Тукай һәм Ютазы районнары.<br>Мондый хәл булырга тиеш түгел. Мәгариф һәм фән министрлыгына муниципалитетлар белән берлектә муниципаль мәгариф органнарының эш системасын тикшерергә, педагогика өлкәсендәге стандартларга туры килүне тәэмин итүче технологияләрне һәм методик алымнарны камилләштерергә кирәк. | 25.1. «Белем бирү һәм тәрбия өлкәсендәге проблемалар турында» темасына «түгәрәк өстәл».<br><br>25.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Единая Россия» депутат фракциясе утырышында «Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында»гы мәсьәләне карау.<br><br>25.3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында «2023 елда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады хакында»гы мәсьәләне карау. | 2024 елның мае<br><br>2024 елның II кварталы<br><br>2024 елның мае | Х.Г. Миргалимов<br><br>Ю.З. Камалтынов<br><br>А.Р. Зарипов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Илебездә игълан ителгән Укытучы һәм остаз елында республиканың барлык педагогика өлкәсе хезмәткәрләренә кагылышлы зур эш алып барыла. Бу укытучыларның югары абруен һәм аларның хезмәтенең әһәмиятен тагын бер кат дәлилли. | | | |
| 26. | Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыкларның туган телен саклау, үстерү мәсьәләләре буенча комиссия тел мохитен саклауга зур өлеш кертә. Хакимият органнары, иҗтимагый оешмалар белән 100гә якын уртак проект булдырылды. Әлеге чаралар татар телен генә түгел, республикада яшәүче башка милләт телләрен – рус, чуваш, удмурт, мари, мордва телен үз эченә ала. Бу эш милли мәгариф һәм мәдәният өлкәсе өчен олы әһәмияткә ия. Аны әйдәп бару өчен Марат Готыф улы Әхмәтовка рәхмәтемне белдерәм. | 26.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан оештырылган һәм аның катнашындагы чараларда катнашуы. | 2023, 2024 еллар дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| 27. | Башлангыч медицина ярдәме күрсәтү пунктлары сәламәтлек саклау системасының әһәмиятле буыны булып тора. Биредә кадрлар җитмәү мәсьәләсе элеккечә үк актуаль булуын билгеләп үтәсем килә.<br>Бу исә булган персоналга өстәмә эш йөкләүгә китерә, ә бу, үз чиратында, медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфатына турыдан-туры йогынты ясый.<br>Халыкка диспансеризация уздыру эшен киләчәктә дә дәвам итәргә кирәк. Хатын-кызлар һәм бала табарга карар кылган гаиләләр, шулай ук ерак авылларда яшәүчеләр аерым игътибар таләп итә. | 27.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында «Амбулатор-поликлиника учреждениеләрендә беренчел медицина ярдәме күрсәтүне оештыру һәм аның сыйфатын тәэмин итү турында»гы мәсьәләне карау. | 2024 елның июне | С.М. Захарова |
| 28. | ГТО системасын актив кулланышка кертү физик культураны һәм спортны үстерүгә зур этәргеч | 28.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты | 2024 елның феврале | С.М. Захарова |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | бирә. Бүгенге көндә ГТО мәгълүмат системасында республиканың һәр дүртенче кешесе теркәлүгә дә карамастан, әлеге нормативларны үтәгән кешеләр саны буенча безгә ил күләмендә беренчеләр сафында булу өчен бик күп тырышырга кирәк әле.<br>Спорт министрлыгы, муниципалитетлар башлыкларының бурычы – теләге булган һәр кешегә ГТО нормативларын бирүдә үз көчен сынап карар өчен тиешле барлык шартларны булдыру. Әлеге чаралар даими нигездә уздырылырга тиеш һәм һәркемгә алардан файдалану мөмкинлеген бирү зарур. | утырышында «Татарстан Республикасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО)» физкультура-спорт комплексын гамәлгә ашыру турында»гы мәсьәләне карау. | | |
| 29. | Инвалидларга, өлкән яшьтәге кешеләргә, балалы гаиләләргә һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга булышу – безнең төп бурычларның берсе. | 29.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы утырышында инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау мәсьәләләре өлешендә «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына мониторинг ясау йомгаклары хакында»гы мәсьәләне карау.<br>29.2. Мохтаҗ гражданнарга адреслы ярдәм күрсәтү, хәйрия чараларында катнашу. | 2023 елның декабре<br>2023, 2024 еллар дәвамында | С.М. Захарова<br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| 30. | | 30.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты утырышында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында һәм җирле үзидарә органнарында норматив хокукый актларга коррупциягә каршы экспертиза уздыру турында»гы мәсьәләне карау. | 2024 елның II кварталы | Ш.Ш. Яһудин |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 31. | | 31.1. Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы нигезләмәләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы органнарының гражданн җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеге. | 2023, 2024 еллар дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |